**1970-1977 еллар.**



1970 ел. Кадыбаш урта мәктәбенең беренче чыгарылышы була. Анда 45 егет һәм кыз өлгергәнлек аттестаты алып чыгалар. 10 А класс класс җитәкчесе Галина Рәхилә Абдуразгиевна, 10 Б класс класс җитәкчесе Ахмадиева Әлфия Хаматовна булалар. Бу чыгарылыштан Бәхтегараева Фәридә Казан медицина институтына, Ситдикова Тәскирә Казан авыл хуҗалыгы институтына, Багаутдинова Роза Бөгелмә кооператив техникумына, Файзуллина Дилүсә Казан Дәүләт университетының читтән торып уку бүлегенә, Исмагилов Мөнир мореходное училищега, Низамова Рәсимә Казан Дәүләт университетының читтән торып уку бүлегенә, Батырманова Айсылу Бөгелмә сәүдә техникумына укырга керәләр



Ә шул чыгарылыштан Рамазанов Илфат Совет Армиясе сафларыннан кайткач, туган мәктәбендә хәрби хәзерлек фәнен укыта башлый. Бүгенге көндә ул Кадыбаш җирле үзидарә башлыгы вазыйфасын башкара.Укытучылар коллективында да үзгәрешләр була. Физика - математика укытучысы Яппаров Мөшәвир Габдуллович Кырынды 8 - еллык мәктәбенә директор итеп күчерелә.

Физика - математика фәннәрен укытырга Казан Дәүләт педогогия институтын яңа гына тамамлаган яшь семья - Салагыш егете Низам Мирзаянович һәм Чистай кызы Дания Касыймовна Шәйхетдиновалар киләләр Укучыларга авыл хуҗалыгы техникасын өйрәтүдә яшь механизатор, армия сафларыннан демобилизацияләнгән үз эшенең остасы Яңа Сләк авылы егете Мәҗитов Рәшит кабул ителә.

Минзәлә педогогия училищесын тәмамлап чыккан үзебезнең авыл кызы Башарова Гөлзирә пионервожатый булып, Сибатова Фәния башлангыч класс укытучысы булып билгеләнәләр.

Кадыбаш урта мәктәбендә Тула өлкәсе Щекино шәһәреннән килгән яшь кыз Жаннета Олеговна Ранкова укучыларда рус теленә мәхәббәт тәрбияли, аларны бу бөек телнең нечкәлекләренә төшендерә.

Хезмәт тәрбиясе бирүдә өлеше зур булган хезмәт укытучысы Казандагы мастерлар хәзерләү мәктәбен тәмамлаган Рамазанов Вәсил Галиевичның өлеше зур була.

1972 елда, озак еллар математика укытканнан сон, укытучы Сорокина Зөләйха апа Таҗетдиновна тантаналы итеп лаеклы ялга озатыла.

Тарих - җәмгыять белеме укытучысы Ахмадиева Әлфия Хаматовна күчеп китү сәбәпле, тарих укытучысы итеп Хөршидә апа Мәүләветдиновна билгеләнә.

Химия фәнен озак еллар эшләгән тәҗрибәле укытучы кешелекле, гади булуы белән аерылып торучы иптәш Даутова Фәһимә Закировна укыта. Биология буенча Башкирия кызы Ханнанова Динира алып бара.

Мәктәптә завуч булып элекке завуч Аюпова Җәмилә Аюповнанын кучеп китүеннән сон, тәҗрибәле методист, зур эрудициягә ия булган Нурания Гарифовна Мифтахова алып бара. Урта мәктәп булган интернат та зурая. Бу елларда интернатта тәрбияче булып Гарифуллина Зәйнәп Шаймуратовна, үзебезнен мәктәпне тәмалаган кызлар Габбасова Гөлсинә, Закирова Гөлсинә, Гумәрова Розалияләр эшлиләр. Рус теле укытучысы, Арча педучилищесын бетереп, КГПИ да читтән торып укучы, Девятерня кызы Шарипова Дилүсә Фазыловна да хезмәт юлына беренче адымны Кадыбаш урта мәктәбендә атлый.



Аюпова Җәмилә Аюповна

Бу чорда мәктәптә 2 чит теле укытыла. Аны Казан кызы белән урта мәктәп тәмалаган ягымлы, эш сөючән Флера Минзянова укыта; укучылар бу үзенчәлекле инглиз телен тиз яратып өлгерәләр, тик Флера ,КГПИ ның чит телләр факультетына укырга керү сәбәпле, бу кызыклы фән укытылмый башлый.
1976-1978 уку елында мәктәпнең методик кабинеты районда алдынгы кабинетлардан дип бәяләнә.

Партиябезнен һәм дәүләтебезнен балалар турында кайгырту турындагы карарларына җавап буларак, безнең мәктәптә дә озайтылган көн группасы ачыла.

Группаларның берсендә озак еллар эшләгән тәҗрибәле педагог иптәш Заһидә Фассаховна Зайнетдинова эшли, анын эш тәҗрибәсе район мәктәпләренең озайтылган көн группаларында өйрәнелә. 2 группага Шәймәрданова Кадрия , Маннанова Мөнҗия, Сафина Розалия, ә 1977 нче елда үзебезнен мәктәпне тәмамлаган Ситдикова Зөлфия, Исмагилова Зөлфия педогогия һәм культура агарту училищеларын тәмамлаган, һәр нәрсәгә осталыгы белән аерылып торучы яшь белгеч Габбасова Гөлфәнияләр җитәкчелек итә.

Физика - математика укытучылары Шәйхетдиновлар кучеп киткәч, бу фәнне яшь математиклар Казан дәүләт педогогия институтын тәмамлаган омтылышлы, эш сөючән кызлар Хакимова Розалия, Хисматуллина Әлфияләр укыта.

Физика фәнен яшь белгечләр Шаймарданова Кадрия һәм Зиятдинова Люция һәм читтән торып ЕГПИ ның физика- математика факультетында укучы иптәш Тимеркаев Фәһим Муллахметович укыта.

Мәктәп зурая, усә бара, яңа белгечләр кабул ителә. Бу елларда мәктәптә лаборант булып Яңа Эсләк авылы кызы Фәтхиева Гөлсинә Минегалиевна һәм библиотекарь булып Ситдикова Зөлфия Илдаровна эшли.

Класстан тыш тәрбия буенча мөдир булып Буа районы Кильдураз авылы кызы Гиззатуллина Фирая,ә биология, география фәннәре буенча белем бирүдә, балаларда туган илгә мәхәббәт тәрбияләүдә һәм табигать серләрен төшендерүдә ару-талуны белмичә Рафаэль Гиззатуллин Равилович эшли. Нәниләргә белем серләренә беренче булып ишек ачучы Ижболдина Мәмдүдәнен хезмәте дә игътибарга лаек була.

Тарих фәне буенча укытучы Галина Рәхилә Абдуразиевна эшли.

Мәктәптә 1971 елдан башлап Гумерова Алмазия эшли. Ул узенең хезмәт юлын өлкән пионервожатый булып башлый, читән торып КГУ нын татар теле бүлеген тәмамлый, тарих, татар теле фәннәрен укытып, үз эшенең остасына әверелә.

Балаларнын туган илнең матурлыгын күрергә, алардан кешелекле нечкә хисләр, патриотизм, гуманизм, интернационализм тәрбияләүдә күп көч куючы үзебезнен авыл кызы КГУ студенткасы Закирова Гөлсинә Сабировна бу елларда татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, үз эшенен остасына әверелә бара.

Техникага мәхәббәт тәрбияләүдә, яшьләрне авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре итеп тәрбияләүдә техниканың докторы дип аталырга лаеклы булган Ахмадишин Мөхәмәтнур Муллахмәтовичның 1970-1978 елларда өлеше зур булды, анын тәҗрибәсе дә РОНО һәм район мәктәпләре тарафыннан хупланды. Пионервожатый Хәкимова Нурия мәктәп пионерларынын дусты, киңәшчесенә әверелә. 1976-77 уку елы мәктәп тарихында иң күнелле,иң унышлы елларның берсе буларак урын алды. Музыка һәм физкультура укытучысы булып эшкә кабул ителгән, Арча педучилещесын тәмамлаган егет Хуҗин Илдус Шамилевичның укучыларда сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләүдә һәм авыл халкына культура хезмәте күрсәтүдә өлеше зур була. Илдуснын тормыш иптәше рус теле укытучысы Роза Хуҗина, рус теле укытучысы яшь белгеч Галина Зюзина һәм үзебезнен район кызы Зирәк Гилязовалар укучыларнын якын дусларына әвереләләр .

Мәктәптә буфетчы һәм балаларны тукландыру өчен зур тырышлык куючы Арсланова Әнисәнең, бу елларда завхоз булып эшләүче, озак еллар эшләп лаеклы ялга чыккан Арсланов Хаҗины алмаштырган Ибраев Заһид Нургалиевичның, интернатта тәрбияче Рәшитова Ләлә Рафиковнаның хезмәтләре зур.

Мәктәптә 40 ел эшләп балаларны коммунистик рухта тәрбияләүдә зур өлеш

керткән һәм лаеклы ялга чыккан башлангыч класс укытучысы Насифуллина Фәрхенурның хезмәт юлы - мәктәбебезнең данлы традицион дәвамы ул.

Бөтен укыту – тәрбия процессын заман таләбенә туры китереп оештырырга омтылып эшләүче, төгәллеге белән бөтен укытучылар һәм укучылар коллективына үз үрнәге белән йогынты ясаучы мәктәп директоры Сафин Нургаян Нурулловичнын хезмәте мәктәп тарихында иң зур урынга лаек. Аның тырышлыгы белән авылда типовой урта мәктәп бинасы салу планлаштырыла һәм ул унынчы бишьеллыкта укучыларны кабул итә.

Укытучылар, ата-аналар җәмәгатчелекнен бердәм, тырыш хезмәте нәтиҗәләр бирә. 1970-78 елларда мәктәпне барысы тәмамлап чыга. Өлгереш 98 - 99 % тәшкил итә. Уку яшендәге балаларда җинаятчелек бөтенләй күзәтелми. Мәктәпне тәмамлаган укучыларнын күпчелеге туган авылда калып колхоз производствосынын төрле тармакларында эшлиләр. Күп кенә яшьләр урта махсус һәм югары белемгә ия булдылар.